**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

14.05.2020 577-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 20 июлендәге 668-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотуга куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрләр килү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны федераль законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотуга куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрләр килү тәртибен раслау турында» 2016 елның 20 июлендәге 668-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотуга куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрләр килү тәртибенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гражданинның мөрәҗәгате һәм дәүләт граждан хезмәткәренең гаризалары әлеге Тәртипнең 1 нче, 2 нче һәм 3 нче кушымталарына ярашлы форма буенча язмача рәвештә төзелә һәм министрга җибәрелә.».

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М. Шәеховка) әлеге Боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков